ЯКШӘМБЕ
14 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 86 (5886)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ВУЗ ЛАРДА ПАРТИЯ-ПОЛИТИК ЭШНЕ КӨЧӘЙТЕРГӘ

Безнең ВУЗ ларыбыз илебезнең хуҗалык һәм культура үсешенә тулы җавап бирә алырлык, югары квалификацияле, югары культуралы, идея-политик яктан нык коралланган белгечләр һәм фән һәм техника работниклары хәзерләп чыгарырга тиешләр. Моның өчен, барыннан да элек, ВУЗ ларның партия оешмаларыннан студентлар, профессорлар һәм укытучылар арасында партия-политик, масса-аңлату эшләрен яхшы итеп кую һәм укуда коммунистларның авангардлык ролен тәэмин итү таләп ителә.

Казан ВУЗ лары янындагы партия оешмаларының күпчелеге бу бурычларны дөрес аңладылар һәм студентлар арасында политик-тәрбия эшләрен сизелерлек яхшырттылар. Шуның нәтиҗәсендә ВУЗ ларда укуларның сыйфаты һәм фәнни-тикшеренү эшләре яхшырганнан-яхшыра бара. Мисаль өчен Финанс-Экономика институты янындагы башлангыч партоешманың эшен күрсәтергә мөмкин. Бу оешма партия-политик һәм масса-аңлату эшләрен укыту-тәрбия һәм хуҗалык эшләре белән ныклы рәвештә бәйләп алып бара. Факультет, кафедра җитәкчеләренең, укытучыларның киңәшмәләре үткәрелә.

Институтның кафедралары, факультетлары арасында социалистик ярыш киң җәеп җибәрелгән һәм барлык студентлар да индивидуаль ярыш договорлары белән чолганып алынганнар. Коммунист студентлар укуда авангардлык роле уйныйлар. Мәсәлән, быел кышкы имтиханнар вактында барлык укучылар фәннәрнең 57,1 процентын отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырсалар, коммунист студентлар фәннәрнең 83,6 процентын яхшы һәм отлично билгеләренә тапшырдылар.

Коммуналь-Төзелеш Инженерлары институтында да укытучылар һәм студентлар коллективын идея-политик тәрбияләү эше шактый яхшырды. Бу институтта укучы студент коммунистлар фәннәрне үзләштерүдә большевистик үрнәк күрсәтәләр.

Шуның белән бергә студентлар һәм укытучылар арасында партия-политик эшләрне тиешле югарылыкка куя алмаучы партия оешмалары да бар әле. Мәсәлән, Медицина институтында студентлар арасында дисциплинаның торышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Бу институтта студент коммунистлар укуда авангардлык роле уйнамыйлар, студентлар февраль аенда 3 мең сәгать, март аенда 1.700 сәгать дәрес калдырганнар. Биредә дәрескә кичегеп килүче һәм лекцияләр вактында кирәксез эшләр белән шөгыльләнүче студентларны еш кына очратырга мөмкин. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Моның сәбәбе институт партия оешмасының партия-политик эшне яхшы итеп куя алмавында һәм укыту-тәрбия эшләре белән тирәнтен шөгыльләнмәвендә. Коммунист студентларның авангардлык рольләрен тәэмин итү мәсьәләсе бер тапкыр да бюро утырышында һәм партия җыелышында тикшерелмәгән.

Химия-Технология, Авыл хуҗалыгы һәм Ветеринария институтларында да партия-масса эшләренең торышы һәм укуларның сыйфаты өчен көрәш канәгатьләнерлек түгел. Мәсәлән, Химия-Технология институтының II нче курсында укучыларның 32,9 проценты органик химиядән, I нче курста укучыларның 15,5 проценты югары математикадан өлгермәүләрен бары тик студентлар арасында политик-тәрбия эшләренең һәм укуларның югары сыйфаты өчен көрәшнең йомшак булуы белән генә аңлатырга мөмкин. Бу ВУЗ ларның партия оешмалары киләчәктә партия-политик һәм масса-аңлату эшләрен тамырыннан яхшыртырга, институтта укыту-тәрбия һәм хуҗалык мәсьәләләре белән ныклы рәвештә шөгелләнергә тиешләр.

Партиянең күптән түгел булып үткән район, шәһәр конференцияләрендә делегатлар ВКП(б) ның Молотов райкомы, шәһәр комитеты тарафыннан ВУЗ ларга һәм ВУЗ партия оешмаларына җитәкчелекнең кирәгенчә булмавын каты рәвештә тәнкыйть иткәннәр иде. Шуннан соң узган вакыт эчендә Молотов райкомы конференция карарларын үтәү йөзеннән кайбер эшләр башкарды. ВУЗ ларның партбюро секретарьлары белән югары мәктәпләрдә партия-политик эшләрен оештыру турында, ВУЗ ларның җитәкче работниклары катнашы белән укыту һәм фәнни-тикшеренү эшләрен яхшырту турында киңәшмәләр үткәрде. Партбюро секретарьлары өчен төрле темаларда лекцияләр укылды. Ләкин болар башлангыч эшләр генә әле. Райком ВУЗ ларда партия-масса һәм укыту-тәрбия эшләрен көчәйтү буенча планлы эш алып барырга тиеш.

1938 нче елның 15 нче маенда югары мәктәп работникларының беренче Бөтенсоюз киңәшмәсендә Сталин, Молотов иптәшләр тарафыннан сөйләнгән речьләр, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарлары ВУЗ ларның җитәкчеләрен, партия, комсомол оешмаларын һәм барлык студентлар, укытучылар коллективын укыту-тәрбия эшләрендә яңа җиңүләргә рухландырдылар. Профессорлар, укытучылар һәм студентлар арасында социалистик ярыш киң колач алды. Күпчелек профессорлар, укытучылар лекцияләрнең сыйфатын яхшырту өчен, студентлар отлично һәм яхшы билгеләренә генә уку өчен көрәшәләр. ВУЗ партия оешмаларының сугышчан бурычлары: югары мәктәпләрнең алдынгы кешеләре тарафыннан алып барыла торган бу көрәшнең башында торудан һәм аны тагын да киң җәеп җибәрүдән гыйбарәт.

ТАСС НЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

Америкада чыга торган „Нью-Йорк таймс" газетасының Берлиндагы хәбәрчесе „Нарвикны оккупацияләгән Германия гаскәрләренең күпчелеге Ленинград һәм Мурманск аркылы тимер юл буйлап килгәннәр" дигән хәбәр биргән иде.

„Нью-Йорк таймс" ның хәбәре бөтенләй дөрес түгеллекне һәм провокацион уйдырма икәнлекне белдерергә ТАСС ның вәкаләте бар.

Петсамоны финнәргә тапшыру турында акт

СССР белән **Финляндия** арасында 1940 нчы елның 12 нче мартында төзелгән Солых Договорына теркәлгән протоколның 7 нче статьясенә туры китереп, Кызыл Армия командованиесе тарафыннан билгеләнгән махсус уполномоченныйлар: полковник **Л. С. Сквирский** һәм 3 нче ранг хәрби инженер **М. М. Федоров**, шулай ук Финляндия армиясе командованиесе тарафыннан билгеләнгән махсус уполномоченныйлар: капитан **А. Пеннанен**, полиция исправнигы **Куукканен** һәм инженер **Нордин** бу актны түбәндәгеләр турында төзеделәр:
—**СССР** белән **Финляндия** арасында 1940 нчы елның 12 нче мартында төзелгән Солых Договорына теркәлгән протоколның 6 нчы статьясе буенча **Петсамо** шәһәре һәм **Лиинахамари** порты, коммуналь хуҗалык һәм җирле промышленность корылмалары һәм җиһазлары белән берлектә, шушыңа теркәлгән исемлек буенча, Финляндия армиясе командованиесе тарафыннан билгеләнгән махсус уполномоченныйлар кулына тапшырылалар.

Бу актка кул куйган һәр ике як, Кызыл Армия командованиесенең **Петсамода** телефон-телеграф станциясен, ике электр станциясен, электр челтәрен, водопроводны, күп кенә йортларның пар белән җылыту системасын, ә **Лиинахамари** портында причалларны төзәткәнлеген һәм бу предприятиеләрнең барсының да Финляндия армиясе вәкилләренә эшкә ярарлык хәлдә тапшырылганлыгын раслыйлар.

Бу акт рус һәм фин телләрендә, ике данә итеп, 1940 нчы елның 9 нчы апрелендә, 12 сәгат 40 минутта **Петсамода** төзелде.

Кызыл Армия уполномоченныйлары—*Сквирский, Федоров.*

Финляндия армиясе уполномоченныйлары—*А. Пеннанен, Вальтер, Нордин, Куукканен.*

Колхозларның һәм ялгыз хуҗалыкларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшырулары турында

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары

Бөртекле культураларның җәмагат чәчүлекләрен тагын да киңәйтү, иген уңышын күтәрү һәм сөрергә яраклы булган барлык җирләрне тулысынча эшкәртү белән колхозларның кызыксынуларын көчәйтү, шулай ук дөрес чәчү әйләнешләре кертү теләге белән,—ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карар бирәләр:

1. Колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыруларын бу культураларны чәчү планы буенча исәпләүдән гыйбарәт булган хәзерге тәртипне бетерергә.

2. 1940 нчы елгы уңыштан башлап колхозлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлыкны һәм дөгене колхозларга беркетелгән сөрү җирләренең һәрбер гектары исәбеннән тапшыралар дип билгеләргә.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыруны исәпләгәндә сөрү җирләре исәбенә түбәндәгеләр керәләр: түтәл бакчалары, шулай ук дәүләт планы буенча (сөрелми яткан җирләрне сөрү, сазлыкларны киптерү һәм куаклыкларны арчу) үзләштерелергә тиеш булган яңа җирләр (үзләштерүнең икенче елында). Мамык, шикәр чөгендере, житен, киндер, цикорий, тәмәке, махорка, эфир-май, сүсле яңа культуралар, дару үләннәре, кольза, сафлор, кориандр, анис, мәк, рыжик, арахис, ляллеманций, перилла, каучуклы культуралар чәчелгән, шулай ук тут, фрукта, җиләк, виноград культуралары һәм субтропик культуралар утыртылган җирләр бөртекле ашлыкны һәм дөгене дәүләткә мәҗбүри рәвештә тапшыруны исәпләү җирләре исәбенә кермиләр, бу культураларның продукциясе дәүләткә хәзерге тәртиптә тапшырыла.

3. Союзный һәм автономияле республикаларның халык комиссарлары советларын, край һәм өлкә башкарма комитетларын, ВКП(б) Өлкә комитетларын һәм край комитетларын һәм союзный республикалардагы компартияләрнең үзәк комитетларын, дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча край, өлкә, республика өчен билгеләнгән нормаларга туры китереп,—колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшырулары буенча районнар өчен еллык нормалар билгеләргә һәм СССР Совнаркомы янындагы Экономсовет тарафыннан расланганнан соң аларны көньяк районнар буенча 1940 нчы елның 20 нче маена һәм башка районнар буенча 1940 нчы елның 1 нче июненә иглан итәргә мәҗбүр итәргә. Районнар өчен нормалар билгеләгәндә шул өлкә, край һәм республика өчен билгеләнгән нормадан югарырак яки түбәнрәк итеп билгеләүгә юл куярга, ләкин колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшырулары буенча гомумән өлкә, край һәм республика өчен билгеләнгән норма тулысынча сакланырлык булырга тиеш.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча СССР Совнаркомы янындагы Экономсовет тарафыннан районнар буенча колхозлар өчен расланган еллык нормаларны районнардагы барлык колхозлар өчен дә кулланырга.

Дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча, МТС лар хезмәт күрсәтми торган колхозлар өчен билгеләнгән нормалар шул районда МТС лар хезмәт күрсәтә торган колхозлар өчен билгеләнгән нормадан 15 процент югарырак булырга тиеш.

Бөртекле ашлык орлыкчылыгы колхозлары (район орлыкчылык хуҗалыклары) дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлыкны һәм дөгене культуралар буенча һәрбер культура өчен чәчү планы белән билгеләнгән мәйданга карата пропорциональ рәвештә тапшыралар.

4. Колхозларда бөртекле культуралар чәчүлекләре чынлыкта күпме булуга карамастан, колхозларның дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыруларының шушы карарның 2 нче пункты буенча сөрү җирләренә карап исәпләнгән күләмнәре үзгәртелмичә калалар дип билгеләргә.

5. 1940 нчы елгы уңыштан башлап ялгыз хуҗалыклар һәм кооперативлашмаган кустарьлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлыкны һәм дөгене шул хуҗалыклар файдалануында булган сөрү җирләренең һәрбер гектары исәбеннән, сөрү җирләренең һәрбер гектарыннан шул районда МТС лар хезмәт күрсәтә торган колхозлар өчен билгеләнгән нормадан 0,6 центнер артык булган норма буенча тапшыралар дип билгеләргә.

6. Бөртекле культуралар чәчүлекләре булган колхозлар, эшчеләр, хезмәткәрләр һәм кооперативлашкан кустарьлар дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлыкны һәм дөгене чынлыкта булган чәчү мәйданы исәбеннән, 1939 нчы елны шул районлардагы ялгыз хуҗалыклар өчен яшәп килгән нормалар буенча тапшыралар.

7. 1940 нчы елга мәҗбүри рәвештә бөртекле культуралар тапшыру буенча еллык йөкләмәләрне үтәү өчен түбәндәгечә календарь срокларны билгеләргә (еллык планга карата процентларда):

I. Бөртекле ашлык буенча—колхозлар өчен:

Өлкәләр, крайлар һәм республикалар	Июльдә	Августта	Сентябрьдә	Октябрьдә	Ноябрьдә
I. Ростов, Сталинград, Саратов, Көньяк Казагстан, Көнбатыш Казагстан, Алма-Ата, Воронеж һәм Курск өлкәләре; Краснодар һәм Орджоникидзе крайлары; Кырым, Чечен-Ингушия, Дагстан, Төньяк Осетия, Кабардино-Балкария, Калмык һәм Волга буе немецләре АССР лары; Украина, Азербәйҗан, Әрмәнстан, Грузия, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Таҗикстан һәм Кыргызстан ССР лар.	10	45	40	5	—
II. Чкалов, Куйбышев һәм Пенза өлкәләре; Башкыртстан, Татарстан, Мордовия АССР лар; Казагстан ССР (Көньяк Казагстан, Көнбатыш Казагстан һәм Алма-Ата өлкәләреннән кала)	—	30	40	30	—
III. Москва, Киров, Горький, Рязань, Тула, Тамбов, Орел, Ленинград, Иваново, Ярославль, Калинин, Смоленск өлкәләре; Чувашстан, Мари һәм Удмуртия АССР лар; Белоруссия ССР.	—	25	40	30	5
IV. Свердловск, Молотов, Чиләбе, Омск, Новосибирск, Иркутск, Чита, Архангельск һәм Вологда өлкәләре; Алтай, Красноярск, Хабаровск һәм Приморье крайлары; Коми, Якутия, Бурят-Монголия АССР лар; Карел-Фин ССР	—	15	35	40	10

II. Бөртекле ашлык буенча—ялгыз хуҗалыклар өчен, шулай ук бөртекле культуралар чәчүлекләре булган колхозчылар, кустарьлар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр өчен

Өлкәләр, крайлар һәм республикалар	Июльдә	Августта	Сентябрьдә	Октябрьдә
I. Ростов, Сталинград, Саратов, Көньяк Казагстан, Көнбатыш Казагстан, Алма-Ата, Воронеж һәм Курск өлкәләре; Краснодар һәм Орджоникидзе крайлары; Кырым, Чечен-Ингушия, Дагстан, Төньяк Осетия, Кабардино-Балкария, Калмык һәм Волга буе немецләре АССР лар; Украина, Азербәйҗан, Әрмәнстан, Грузия, Үзбәкстан, Төркмәнстан, Таҗикстан һәм Кыргызстан ССР лар;	20	50	30	—
II. Чкалов, Куйбышев һәм Пенза өлкәләре; Башкыртстан, Татарстан һәм Мордовия АССР лар; Казагстан ССР (Көньяк Казагстан, Көнбатыш Казагстан һәм Алма-Ата өлкәләреннән кала)	—	60	40	—
III. Москва, Киров, Горький, Рязань, Тула, Тамбов, Орел, Ленинград, Иваново, Ярославль, Калинин һәм Смоленск өлкәләре; Чувашстан, Мари һәм Удмуртия АССР лар; Белоруссия ССР;	—	50	50	—
IV. Свердловск, Молотов, Чиләбе, Омск, Новосибирск, Иркутск, Чита, Архангельск һәм Вологда өлкәләре; Алтай, Красноярск, Хабаровск һәм Приморье крайлары; Коми, Якутия һәм Бурят-Монголия АССР лар; Карел-Фин ССР.	—	35	55	10

III. Кукуруз һәм дөге буенча—колхозлар һәм ялгыз хуҗалыклар өчен, шулай ук бөртекле культуралар чәчүлекләре булган колхозчылар, эшчеләр, хезмәткәрләр һәм кустарьлар өчен

Культуралар	Октябрьдә	Ноябрьдә
Кукуруз	40	60
Дөге	35	65

8. Түбәндәгеләр дәүләткә мәҗбүри рәвештә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыруга тартылмыйлар, дип билгеләргә:

а) картаю сәбәпле,—ирләр 60 яшькә һәм хатын-кызлар 55 яшькә җиткән булу сәбәпле хезмәткә яраксыз булган кешеләрнең хуҗалыклары,—әгәр аларның шул хуҗалыкта эшләүче, хезмәткә яраклы семья членнары булмаса, шулай ук үзләренең уллары действительный гаскәри хезмәттә булган, ә семьяларендә 7 яшькә кадәр балалары белән хатыннары калган, картайган ирләрнең һәм хатын-кызларның хуҗалыклары;

б) кызыл армеецларнең хуҗалыклары,—әгәр дә семья башлыгы действительный гаскәри хезмәттә булса, ә семьядә 7 яшькә кадәр булган балалары белән хатыны калган булса;

в) социаль тәэминат яки социаль страхование органнары тарафыннан беренче һәм икенче инвалидлык группаларына кертелгән сугыш һәм хезмәт инвалидларының хуҗалыклары.

9. Дәүләткә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча бу карар белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәү—һәрбер колхозның һәм ялгыз хуҗалыкның беренче чираттагы бурычы һәм ул беренче сугылган ашлык белән үтәлергә тиеш, шуның белән бергә, йөкләмәләрне үтәмәүчеләргә закон буенча җәза биреләчәк.

10. Властьның җирле органнарының һәм хәзерләү органнарының бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча колхозларга һәм ялгыз хуҗалыкларга гектар исәбеннән булган нормадан артык йөкләмә салулары һич шиксез тыела.

Дәүләткә бөртекле ашлык һәм дөге тапшыру буенча йөкләмәләрне үтәгәннән соң артып калган барлык ашлык тулысынча колхозларның, колхозчыларның һәм ялгыз хуҗалыкчыларның үз ихтиярында кала.

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе В. МОЛОТОВ.

ВКП(б) Үзәк Комитеты Секретаре И. СТАЛИН.

11 апрель, 1940 ел.

СОҢГЫ СӘГАТТӘ

РЕЙТЕР АГЕНТЛЫГЫНЫҢ ЮККА ЧЫГАРУЫ

ЛОНДОН, 13 апрель. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең авиация министрлегенең рәсми вәкиле, Англия самолетларының Шлезвиг-Гольштейндагы кичрәк бер станцияне бомбага тотулары турында Германиянең информация бюросының белдерүе дөрес түгеллекне әйткән.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ НАРВИККА ҺӨҖҮМЕ

БЕРЛИН, 13 апрель. (ТАСС). Германиянең информация бюросы Англиянең һава көчләре берләшмәләренең кичә кич белән Нарвик портына һәм шәһәренә һөҗүм ясаганлыкларын хәбәр итә. Бомбаларның берсе дә билгеләнгән урынга төшмәгән. Германиянең һава оборонасы көчле ут белән җавап биргән. Дошман һөҗүмне кабатламаган һәм көнбатыш юнәлешкә китеп качкан.

НАРВИККА ГЕРМАНИЯДӘН ЯҢА ГАСКӘРЛӘР КИЛҮ

БЕРЛИН, 13 апрель. (ТАСС). Германиянең информация бюросы үткән төнне Норвикка Германиядән яңа гаскәрләр килгәнлекне хәбәр итә.

ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты һәм Татарстан Совет Язучылары Союзы

Бүген, 14 нче апрель кич 7 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта, эпохабызның бөек шагыйре **Владимир Владимирович Маяковскийның** үлүенә ун ел тулуга багышланган җыелыш үткәрәләр.

Җыелышка керү өчен билетлар ВКП(б) райкомнары аркылы таратыла.

15 нче апрель, кич 6 сәгатьтә Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы, 25) хезмәт ияләре депутатлары

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫНЫҢ 2 нче СЕССИЯСЕ ЧАКЫРЫЛА

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты.

ТАТАРСТАН БАСУЛАРЫНДА

КЫР ЭШЛӘРЕ МАССОВЫЙ ТӨС АЛА

ПУЧЫ, 12 апрель. **(Телефон буенча).** Калинин районының 40 колхозы кыр эшләренә кереште. „Ташьелга“ колхозы 17 гектар, Киров исмендәге колхоз 12 гектар, Сталин исмендәге колхоз 10 гектар бодай чәчтеләр инде. „Лена“, „Беренче Май“, „Партизан“, „Комбайн“ һәм Тельман исмендәге колхозлар да чәчү эшенә керештеләр.

„Кызыл байрак“ колхозында 4 трактор язгы сөрү эшенә кереште.

Герасимов.

ЮТАЗЫ, 12 апрель. **(Телефон буенча).** Районның 70 колхозыннан 34 сендә тырмалау, язгы сөрү һәм культивацияләү эшләре бара. Хәзер районда 1.300 гектар җир тырмаланды һәм 300 гектар сөрелде инде. „Көрәш бүләк“ колхозы 260 гектар мәйданда тырмалау, 30 гектар мәйданда сөрү үткәрде. Буденный исмендәге колхоз 265 гектар тырмалады, 13 гектар сөрде. „Яссы Тугай“ колхозы 65 гектар тырмалады, 371 гектар культивацияләде инде.

Язгы кыр эшләре „Балан Түбә“ колхозында (председателе иптәш Әхметов) кыр эшләре оешканлык белән бара. Гәрәев, Шәфигуллин һәм Миңлеханов иптәшләр тырмалауда норманы 115—120 процент итеп үтиләр.

„Кызыл бүләк“ колхозында 2 трактор, „Авангард“ колхозында 4 трактор сөрү эшләренә керештеләр.

Галиев.

Уҗымнарны тукландыру башланды

МИНЗӘЛӘ, 12 апрель. **(Телефон буенча).** „Алга“ колхозында Афзалов һәм Шәрипов иптәшләрнең бригадалары 10 ар гектар мәйданда уҗымнарны тукландыру үткәрделәр. „Үрнәк“ колхозында иптәш Галләмов бригадасы 8 гектар уҗым тукландырды.

Агрономнар һәм агротехниклар барлык колхозларда уҗымнарның торышын тикшерделәр.

Уҗымнарның күрнеше яхшы. Аерым колхозларда уҗым мәйданының 5—6 проценты һәлак булу фактлары да бар.

Районның күп кенә колхозларында кыр эшләре кызу рәвештә бара. „Свобода“ колхозында (председателе иптәш Степанов) туңга сөрелгән мәйданның 204 гектары тырмаланды. Хәзер колхозда культивацияләү һәм аерым участкыларда чәчү эшләре башланды.

Агроном *Ерашов.*

ТРАКТОРЛАР ЭШКӘ БАШЛАДЫЛАР

Минзәлә районының Маткавыш МТС ы язгы кыр эшләренә кереште. 8 нче трактор бригадасының тракторчысы иптәш Цыганцов 10 нчы апрельдә культивацияләү нормасын 32 гектар урнына 37 гектар итеп үтәде. 7 нче бригада тракторчысы иптәш Нуруллин „Красный броневик“ колхозында язгы сөрү эшендә беренче көндә үк норманы 100 процент үтәде.

Шулай ук „Красный Октябрь“, Дмитров исмендәге, „Красный Ик“ һәм „Возрождение“ колхозларындагы 1 нче, 3 нче, 4 нче һәм 6 нчы трактор бригадалары да кыр эшләренә керештеләр.

(ТатТАСС).

КЫР ЭШЛӘРЕНӘ КЕРЕШТЕЛӘР

Теләче районында кыр эшләре башланды. 13 нче апрельдә „Марс №2“, „Новая жизнь №1“ һәм Вахитов исмендәге колхозларда клевер чәчә башладылар. Һәрбер колхозда туфракның өлгерешен күзәтү постлары оештырылды.

Ширәмәт районының „Память Ленина“, „Красный Зай“, „Кама“ колхозлары һәм башкалар 10 нчы апрельдә язгы сөрү эшенә керештеләр. 11 нче апрельдә Кызыл Чапчак МТС ының иптәш Соловьев җитәкчелегендәге трактор бригадасы кыр эшләренә кереште.

„Память Ленина“ колхозы сабанчылары А. Бушев, А. Зубрилов, М. Подгорнов, Чайников һәм башка иптәшләр норма буенча билгеләнгән 1,25 гектар урнына һәр көнне 1,4—1,5 гектар җир сөрергә йөкләмә алдылар.

Эшнең беренче көнендә үк Варвара иптәш Сорокина 1,4 гектар җир сөрде.

Мамадыш районы колхозларында язгы кыр эшләре башланды. „Красная Нива“ колхозы кыр эшләрен районда беренче булып башлады. 11 нче апрельдә бу колхоз кырларында 60 баш ат эшләде. Бу көнне колхозда барлыгы 25 гектар җир сөрелде һәм 13 гектар җир тырмаланды. 12 нче апрельдә 25 гектар җир сөрелде һәм 22 гектар җир тырмаланды.

„Прикамский“ һәм „Победитель“ колхозлары да язгы кыр эшләрен башладылар.

11 нче апрельдә трактор бригадалары кырга чыктылар. „Кызыл флаг“ колхозында тракторчылар өчен бик яхшы итеп җиһазландырылган 3 вагон: күчмә ашханә, 8 кешелек йоклау вагоны һәм культвагон хәзерләнде. Культвагонда шашкалар, шахматлар, газеталар һәм журналлар бар.

(ТатТАСС).

АРЧА, 13 апрель. Тельман исмендәге колхоз клевер чәчә башлады. Беренче көнне үк 45 гектар клевер чәчелде. 14 нче апрельдә Масра һәм Батыр Курса колхозлары да клевер чәчүгә керешәләр.

(ТатТАСС).

ТРАКТОРЧЫЛАР ЯЗГЫ СӨРҮ ЭШЕНӘ КЕРЕШТЕЛӘР

Әлмәт МТС ының трактор бригадалары язгы кыр эшләренә керештеләр. 12 нче апрельдә „Зәй“ колхозында тракторлар белән 58 гектар, „Морат“ колхозында 55 гектар җир сөрелде. „Зәй“ колхозында тракторчылардан Юсупов һәм Саримов иптәшләр норманы 115 процент итеп үтиләр.



Татсоюзның китап складны язгы чәчү кампаниясенә карата республиканың төрле районнарына китаплар җибәрә. Рәсемдә: К. Закиров һәм П. Михайлова иптәшләр Красный Бор районына җибәрү өчен китаплар сайлыйлар.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Кошчылык фермасы оештырырга булдылар

ИСКЕ КУАК, 12 апрель. **(Махсус хәбәрчебездән телефон буенча).** „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Халык Комиссарлары Советы карары урнаштырылган газеталар алыну белән, Иске Куак авылы „Ленинский путь“ (Шөгер районы) колхозында партия, комсомол һәм колхоз активының гомуми җыелышы үткәрелде. Җыелышта 70 кеше катнашты. Җыелыш гаять югары активлык белән үтте. Колхозчы Михаил иптәш Зиновьев:

— „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында ВКП(б) Үзәк Комитетының һәм СССР Халык Комиссарлары Советының карары колхозларны тагын да ныгытуга, колхозчыларның тормышын тагын да яхшыртуга юнәлдерелгән. Ул, авыл хуҗалыгы продуктларын хәзерләүдә һәм сатып алуда моңа кадәр яшәп килгән җитешсезлекләрне тамырыннан бетерәчәк. Без, колхозчылар, бу карарны алкышлап каршы алабыз. Безнең колхозда атчылык, сарык һәм дуңгыз асраучылык фермалары бар инде. Мин тагын кош асраучылык фермасы оештыру турында тәкъдим итәм. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар,—ди.

Аннары иптәш Шуманев сүз ала:

— Бу карар колхозчылар турында Сталинчыл кайгыртучанлык белән сугарылган. Колхозчылар турында өзлексез кайгыртучанлык күрсәтү өчен партиябезгә, хөкүмәтебезгә һәм иптәш Сталинга күп рәхмәт. Мин иптәш Зиновьевның тәкъдимен яклыйм. Кошчылык фермасы өчен бездә бер нинди дә өстәмә расход таләп ителми. Бездә ел саен ашлыктан бик күп отход әрәм була. Кош асраучылык фермасы булса бу отходның бер бөртеге дә әрәм булмас иде. Кошчылык фермасын, һич кичекмәстән, оештырырга кирәк,—ди.

Җыелышта чыгып сөйләүче башка иптәшләр дә карарны зур күтәренкелек белән каршы алганлыкларын әйттеләр. Җыелыш колхозда тавык асраучылык фермасы оештыру һәм бу мәсьәләне тизлектә колхозчыларның гомуми җыелышы карамагына кую турында карар чыгарды.

М. Хәмидуллин.

КОЛХОЗЧЫЛАР ПАРТИЯ ҺӘМ ХӨКҮМӘТ КАРАРЫН ЯХШЫ ДИП ТАБАЛАР

Кукмара районы колхозларында „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын өйрәнү киң җәелде.

Күп кенә авылларда колхозчыларның җыелышлары булды. Ворошилов исмендәге, „Күргәзмә“, „Тигезлек“, „Иошкар Кня“ колхозларында һәм башкаларда колхозчылар карарның текстын кычкырып укуны зур кызыксыну һәм игтибар белән тыңладылар. Җыелышта катнашучылар колхозларны ныгыту эшендә бу карарның зур әһәмияте барлыгын әйттеләр һәм барлык колхозчыларны шушы карарны үтәү өчен большевикларча көрәшергә чакырдылар.

***

ВКП(б) ның Кайбыч райкомы 3 урында башлангыч оешма секретарьларының, авыл советы председательләренең, колхоз председательләренең һәм колхоз бригадирларының куст киңәшмәләрен үткәрде. Бу киңәшмәләрдә „Авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сатып алу политикасында үзгәрешләр“ турында партия һәм хөкүмәт карарын колхозчылар арасында аңлату эшен киң җәелдерү мәсьәләсе тикшерелде.

Киңәшмәгә катнашучылар, колхозларны тагын да ныгыту чарасы булган тарихи бу карарны чын күңелдән яхшы дип таптылар.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАР ҺӘМ РЯДОВОЙЛАР СОСТАВЫНА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСМЕ БИРҮ ТУРЫНДА

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Советлар Союзы Герое** исме, **Ленин ордены** һәм **„Алтын йолдыз“** медале бирергә:

1. Кызыл армеец Иван Павлович **Аляевка.**
2. Военфельдшер Иван Федорович **Бирцевка.**
3. Кече лейтенант Федор Захарович **Бабаченкога.**
4. Кызыл армеец Николай Михайлович **Берендеевка.**
5. Кызыл армеец Петр Семенович **Волосовичка.**
6. Кызыл армеец Гармажо Аюров **Гармаевка.**
7. Өлкән лейтенант Борис Семенович **Долгыйга.**
8. Кече командир Захар Афанасьевич **Донийга.**
9. Кече командир Иван Захарович **Дреботка.**
10. Капитан Александр Иванович **Дыдышкога.**
11. Кече политрук Степан Михайлович **Жолобка.**
12. Лейтенант Степан Михайлович **Журавлевка.**
13. Кече лейтенант Иван Семенович **Зарниковка.**
14. Кече командир Денис Архипович **Заяцка.**
15. Шофер Прохор Дмитриевич **Залесовка.**
16. Лейтенант Степан Петрович **Комлевка.**
17. Шофер Иван Дмитриевич **Крайновка.**
18. Кызыл армеец Замхари Асманович **Кунежевка.**
19. Лейтенант Иван Петрович **Марковка.**
20. Өлкән лейтенант Степан Михайлович **Николенкога.**
21. Лейтенант Александр Трофимович **Осипенкога.**
22. Кече командир Иван Арсеньевич **Самойловка.**
23. Кече командир Сергей Васильевич **Семинга.**
24. Лейтенант Иван Федорович **Спиряковка.**
25. Өлкән лейтенант Георгий Филимонович **Хараборкинга.**
26. Кече лейтенант Михаил Семенович **Шамрайга.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
11 апрель, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Кызыл Армиянең гаскәри частьләрен һәм берләшмәләрен СССР орденнары белән бүләкләү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен бүләкләргә:

Кызыл Байрак ордены белән

24 нче укчы дивизияне.

142 нче укчы дивизияне.

13 нче танк бригадасын.

252 нче укчы полкны.

24 нче корпус артиллерия полкын.

227 нче гаубица артиллерия полкын.

302 нче гаубица артиллерия полкын.

7 нче истребитель авиациясе полкын.

10 нчы тиз очышлы бомбардировка авиациясе полкын.

19 нчы истребитель авиациясе полкын.

58 нче тиз очышлы бомбардировка авиациясе полкын.

32 нче аерым разведка авиациясе эскадрильясең.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
11 апрель, 1940 ел.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫН ҺӘМ КЫЗЫЛ АРМЕЕЦЛӘРНЕ БҮЛӘКЛӘҮ

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта кыюлык һәм батырлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумы Кызыл Армиянең начальниклар һәм кызыл армеецлар составыннан, начальниклар составы семьяләре членнарыннан, госпитальләрнең һәм гражданский учреждениеләрнең работникларыннан 12.860 кешене СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләде.

Ленин ордены белән 88 кеше, Кызыл Байрак ордены белән 1.146 кеше, Кызыл Йолдыз ордены белән 3.602 кеше, „Батырлык өчен“ медале белән 3.593 кеше һәм „Сугышчан хезмәтләр өчен“ медале белән 4.431 кеше бүләкләнде.

Барлык бүләкләнүчеләрнең исемлеге „Красная Звезда“ газетасында игълан ителәчәк.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Профессор Н. Ф. Гамалейны Ленин ордены белән бүләкләү турында

Микробиология һәм инфекцион авыруларга каршы көрәш өлкәсендәге күренекле хезмәтләре өчен, шулай ук фәнни, педагогия һәм җәмәгать эшләренең 55 еллыгы уңае белән профессор Николай Федорович ГАМАЛЕЙНЫ Ленин ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
11 апрель, 1940 ел.

АГРОТЕХНИК

Агротехник иптәш Хаялиев Норлат районында күпләргә билгеле. Аны тырышлыгы, эшчәнлеге белән, югары иген уңышы өчен көрәштә бай тәҗрибәсе белән, югары уңыш мастеры булуы белән беләләр. Шушы сыйфатларга ия булганы өчен ул үткән ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашты.

Хаялиев күргәзмәдән яңа тәҗрибәләр, яңа планнар белән кайтты. Илебезнең колхозларында, шул исәптән үзе эшли торган „Активист“ колхозында да югары иген уңышы алу өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр булуын өйрәнде ул монда. Күргәзмәдән кайткач та ул иҗад эшенә чумды. Бик зур мәсьәләләр күтәреп чыкты. Ул: колхоз җирләрен ашлау өчен быел 2.000 тонна торф чыгарырга кирәк дигән мәсьәләне куйды. Бу инициатива яхшы дип табылды. Колхозда торф хәзерләнә башланды. 500 тонна торф чыгарылды да инде.

Иптәш Хаялиев басуларны, аларның туфракларын, кайсы туфракка нинди ашлама кирәклеген тикшерә, өйрәнә, бер өзлексез күзәтүләр алып бара. Шуларның барсы нигезендә ул колхоз басуларының картасын төзеде. Бу картада кайсы участкыда нинди туфрак, анда кайчан, нинди ашлама кертелгән, күпме кертелгән, теге яки бу участкыны күпме тирәнлектә сөрергә кирәклеге һ. б. күрсәтелгән.

— Менә карагыз, бу картаны,—ди ул, үзе кулындагы карандашын картаның кәкре сызыклары буйлап йөртә.—Менә бу „Карамалы чат“ дигән басу. Элек монда кәҗә сакалыннан башка нәрсә үсми дип әйтерлек иде. Гектарына 1,5—2 центнер уңыш була иде. Без аны яхшылап ашлый башладык, һәр гектарга 35 әр тонна тирес керттек. Әйбәтләп эшкәрттек, „кәҗә сакал“ дан чистарттык. Кайберәүләр башта „барыбер шул кәҗә сакалдан башка нәрсә үсмәс“ дип икеләнгәннәр иде дә, нәтиҗә начар булмады. 1937 нче елда бу басуның һәр гектарыннан 22 шәр центнер уңыш алдык“. Ул тагын картага карап, уңышны күтәрүдә агротехника чараларын дөрес үткәрүнең ни чаклы әһәмиятле булуы турында сөйләвен дәвам итә.

— Менә монсы „Богай тавы“ басуы. Бирედә дә бер вакытта да күзгә күренерлек ашлык булмый иде. Туңга сөргәндә без аның һәр гектарына 40 тонна тирес керттек, тирән итеп сөрдек, яз көне тырмалаганда кали тозы белән дә ашладык. Шулай итеп, үткән ел һәр гектардан 14 центнер уңыш алдык. Шушыннан алган экспонатлар Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә җибәрелде.

Иптәш Хаялиев җирле ашламалар хәзерләү, аларны дөрес саклауны оештыруга аеруча зур игтибар бирә. Мондый эшләрне колхозчылар, бригадирлар һәр вакыт аның белән киңәшеп эшлиләр, ул алар белән киңәшә. Колхозчылар аны тыңлыйлар, ул колхозчыларны тыңлый. Шуңа күрә аның авторитеты да зур.

— Җирле ашламаларны җыю гына җитми,—ди агротехник,—аны саклый белергә дә кирәк, ашлама никадәр яхшы сакланса, аның туфракка тәэсире шул чаклы көчле була. Начар ашлама белән уңыш күтәреп булмый.

Аннары ул тагын үз колхозыннан мисальләр китерә, бу колхозның тирә яктагы 3 район колхозларын сортлы орлыклар белән тәэмин итеп торуы турында сөйли, һәр нәрсәне фактлар белән ныгыта.

Агротехника чараларын вактында дөрес үткәрү, җирле ашламалардан киң файдалану нәтиҗәсендә „Активист“ колхозы үткән ел мул уңыш алган һәм быел да Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашуга кандидат итеп расланган. Күргәзмәдә колхозның 18 стахановчысы катнашачак. Алар арасында иптәш Хаялиев та бар.

— Күргәзмәгә катнашуга кандидат булу—бик җаваплы эш ул. Без моны яхшы беләбез. Безнең колхоз членнары быел тагын да югары уңыш алу өчен барлык чараларны күрәләр, ди иптәш Хаялиев.

Колхоз язгы чәчүгә үрнәк булырлык итеп хәзерләнгән. Бөтен нәрсә хәзер. Ефремовчы звенолар план буенча эшлиләр. Агротехник звеноларның эшенә һәр вакыт эшлекле булышлык күрсәтә. Колхозда стахановчылык мәктәбе бар. Аңа иптәш Хаялиев җитәкчелек итә. Ул бу мәктәптә „Югары иген уңышы яулап алу чаралары“, „Ефремовчыларның эш методлары“ һәм башка шундый темаларга 15 тапкыр лекция укыган.

Колхозның бу күренекле эшлеклесе колхозда шундый зур эш алып бару белән бер рәттән, үзе өстендә эшләргә дә вакыт таба. Ул авыл хуҗалыгы турында чыккан һәрбер китапны укып бара, политик белемен күтәрү өстендә тырышып эшли. Һәрбер яңалыкны вактында эләктереп ала белә.

Әйе, бу шулай булырга да тиеш. Колхоз агротехнигы булу—ул зур эш, катлаулы эш, белемле, культуралы булуны, җитезлекне таләп итә торган эш. Иптәш Хаялиев моны яхшы аңлый һәм шулай булырга тырыша.

Х. Хәлилов.

ПАРНИКЛАРДА ЯШЕЛЧӘ ҮСТЕРҮ

Наркомзем планы буенча быел Татарстан колхозларында иртә өлгерә торган яшелчәләр һәм рассадалар үстерү өчен 81 мең рамнан торган парник хуҗалыклары оештырылырга, 2.900 квадрат метр мәйданда теплицалар корылып, аларга яшелчәләр һәм рассадалар чәчелергә тиеш. Шулардан 22.200 рамга кыяр, 2.400 рамга суган, 2.600 рамга редис һәм башка яшелчәләр утыртырга билгеләнде. Алардан калган теплицаларның күпчелегендә кәбестә, помидор рассадалары һәм башкалар үстереләчәк.

Күп кенә районнарда бу планның үтәлеше чиктән тыш начар бара. 17.100 рам 20 нче мартка ук хәзерләнеп, аларга яшелчәләр утыртылырга тиеш иде. Хәлбуки 25 нче мартка колхозларның парник хуҗалыкларында бары тик 600 рамга яшелчә утыртылган, ә теплицаларның берсендә дә утыртылмаган. Теплицаларда һәм парникларда яшелчәләр үстерү өчен техник хәзерлек эше бик йомшак бара. Ремонт эшләре тәгәлләнмәгән, яшелчә өчен туфрак һәм тирес хәзерләү тәмамланмаган.

Лаеш районының Рождественский МТС ы үзе хезмәт күрсәтә торган колхозларда 850 рамнан торган парник хуҗалыкларында яшелчәчелек оештырырга тиеш. Ә хәзергә анда бары тик 250 рамга пыяла куелган. МТС директоры иптәш Галиуллин колхозларда парниклар оештыру мәсьәләсе белән кызыксынмый һәм ул турыда бер нәрсә дә белми. Шундагы „Красный земледелец“ колхозында 200 рам урнына тик 50 рам хәзерләнгән. Сельхозснаб тарафыннан Лаешка җибәрелгән 800 рамны шушы көнгә кадәр колхозлар алмаганнар.

Юдино районында да шундый ук хәл. Анда 20 нче мартка 1.000 рамга утыртылырга тиеш иде. Шулардан 110 гына рамга утыртылган. Район җир бүлеге мөдире иптәш Королев 4 теплицаны февраль ахрына ук корып бетерергә Наркомземга вәгъдә биргән булса да, 23 нче мартка кадәр теплицаларның берсе дә хәзерләнмәгән.

Биектау районында 20 нче мартка кадәр 800 рамга утыртылырга тиеш иде. Анда бер генә рам да хәзер түгел. 1940 нчы елда колхозларда теплица һәм парник хуҗалыкларын төзү планы колхозларга җиткерелмәгән.

Иртә өлгерә торган яшелчәләр һәм рассадалар утырту өчен теплицалар һәм парник хуҗалыкларын оештыру мәсьәләсендә кискен борылыш ясалырга тиеш.

Г. Латыйпов.

ЭПОХАБЫЗНЫҢ БӨЕК ТАЛАНТЛЫ ШАГЫЙРЕ

В. МАЯКОВСКИЙ

„ЯХШЫ!" ПОЭМАСЫННАН

(1927)

Шигырьләр дә,
бурычлар да
безнең эшнең
Мәҗбүр итмәс
барсын да
мактап торырга.
Мин яртысын
сүгәр идем
туган илнең,
Ә яртысын—
теләр идем
әр яндан корырга.
Тоташ бизгәнгә
гади бу көннәрнең
Мин дә чыктым
себерергә
һәм тезәргә.
Мин даньлыклыйм
бүгенгесен
туган илнең,
Өч кат даньлыклыйм мин
булачагын аның
иртәгә.
Яратам мин
зурлыкларын
безнең планнарның,
Һәм аларның
колачының
зур адымга басып барышын.
Мин шатланам
тыңлап
безнең халыкларның
Сугышка һәм эшкә
бара торган маршын.
Күрәм черегәнен
чүпнең
инди җирдә,
Гади булса кай җир,
шул җирләрдә бүген
Күреп торам
мин бер сажен тирәнлектән
Коммуна йортлары
үсеп килгәнлеген.
Тиздән бетәр
көтеп яту
табигатнең
Бәрәр потлы
монсу печән кебек
бүлмәләрен.
Борыла инде
тракторга
авылларның
Катып беткән,
корып беткән
йөрәкләре.
Маңгай эчләрендә
элек
зур планнар
Яткан булса
ярлылыктан
тоткарланып,
Күтәрелә
зәңгәр көндә
хәзер алар
Тимерләр һәм
ташлар булып
формаланып.
Кешеләрнең
хезмәттә һәм сугышларда
Туган язы шикелле,
Туган илне җырлыйм
җырларыйм,
Җырлыйм
Республикамны!

Ә. Исхак тәрҗемәсе.

МАЯКОВСКИЙГА

Күз алдымда
Гигант шагыйрьнең
Батыр йөзе тора нурланып.
Ул бүген дә
Тере шикелле
Китәр төсле хәзер кузгалып.
Менәр төсле кыю
Трибунага
Болгар төсле көчле кулларын;
Укыр төсле
Калын тавышы белән
„Яхшы" сынык утлы юлларын.
Октябрьдән
Соңгы поэзиянең
Корифее иде ул кеше;
Мәңге яшәр
Аның исме,
Мәңге яшәр аның зур эше.
Ул көрәште
Миллионнарны күрде,
Миллионнарны сөйде, мактады;
Иҗадында
Ленин, Сталинны
Нурлы образ итеп саклады.
Ул һәр сүзгә
Яңа хисләр салды,
Яңа ритм тапты аларга;
Ул өйрәтте безне
Бөек көрәш җырын
Ничек итеп матур җырларга.
Аның поэзиясе
Безнең көрәшкә
Цитат биреп торыр алда да,
Дошман өчен
Аның һәр сүзе
Дәһшәтлерәк авыр бомбадан.
Ул Ватанның
Горур патриоты,
Чын солдаты булып яшәде;
Ул чит илдә
Совет паспортын
Шанлы итеп өскә күтәрде.
Күз алдымда
Гигант шагыйрьнең
Батыр йөзе тора нурланып.
Ул бүген дә
Тере шикелле
Китәр төсле хәзер кузгалып.
Ләкин... Бу үк гына...
Тыныч йокла, шагыйрь,
Физик яктан
Син үлсәң дә, эшең үлмәде.
Юлбашчыбыз
Синең турында
Көчле әйтте, матур сөйләде.
Әйе!
Син зур чорның
Зур таланты идең,
Ватан сине мәңге онытмас;
Якты исмең белән
Якты эшеңә
Мәңге, мәңге тузан-тап кунмас.

С. Каратай.

БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУ

1925 нче елның кышы. Москвада матбугат йортында язучылар киңәшмәсе бара. Доклад буенча фикер алышуларда чыккан драматургларның берсе бик кызыклы бер фактка тукталып:

— Бәлки мин ялгышамдыр, мин сөйләгән нәрсә бәлки дөрес түгелдер,—диде.

Шул вакытта иң арткы сафлардан берәү калын тавыш белән:

— Мин раслыйм: дөрес!—дип кычкырды.

Әлеге драматург „Әнә Маяковский раслый" дип сүзен дәвам итә башлаган гына иде, без, залда утыручы яшьләр, гөр килеп калын тавыш килгән якка борылдык һәм ишек янында басып торган озын буйлы мәһабәт кешене күрдек.

Киңәшмәдә аталы язучылар һәм шагыйрьләр күп иде. Ләкин башлап язучылар арасында һәм гомумән бүтән шәһәрләрдән килгән шагыйрьләр арасында Маяковский иҗады белән кызыксынучы, ялкынлы шагыйрьгә мәхәббәт тотучы иптәшләр шул кадәр күп иде, алар тәнәфес вактында Маяковскийны сырып алдылар. Киң коридор халык белән шыгырым тулды.

Үз бәхетләрен матур әдәбиятта сынарга теләгән башлап язучыларның шушындый кайнар мәхәббәтләренә Маяковский, әлбәттә, бик шат иде. Коридорда пальтосын салып ул көлә-көлә:

— Гадәттән тыш киңәшмә ачык. Мин председатель. Кем сүз ала?—диде.

Маяковский белән күңелле генә сөйләшкән вакытта берәү:

— Менә бу иптәш—Казаннан. Татар шагыйре. Сезнең „Сул марш" ны ул татарчага тәрҗемә иткән,—диде.

Ул елларны Маяковскийны бик нык „тәнкыйть" итәләр иде.

Матбугатка кереп сырышкан дошманнар һәм аларга ияргән җиңел акыллы кешеләр Маяковский талантыннан көлеп, аның турында пычрак мәкаләләр язып чыгалар иде. Хәтта әлеге киңәшмәгә дә Маяковский киңәш бирү хокукы белән генә чакырылган иде.

Менә шундый көннәрдә үз әсәрләренең төрле телләргә тәрҗемә ителүен белү— Маяковскийга бик җылы тоелды. Таза гәүдәле, җидди чырайлы шагыйрьнең йөзендә рәхәт дулкынлану сизелде. Әле хәзер генә аңа шигырьләренең украин теленә тәрҗемә ителүе турында сөйләгәннәр иде... инде менә татарчага да бар.

—Ничек чыкты соң?—дип ул миңа сорау бирде.

Мин анда әле яңа гына басылып чыккан „Көнчыгыш йөгергәндә" китабын суздым һәм шул китапка кергән „Сул марш"ны күрсәттем. Русчадагы кебек үк, юллары чәчелеп басылган татарча сүзләргә карап бераз торганнан соң Маяковский:

— Кызганычка каршы, мин татарча укый белмим. Үзегез укып күрсәтегез,—диде.

Маяковский шигырьләрен мин яшьтән үк яратып укый идем һәм шигырьнең үзенчәлеген саклап дөрес укырга тырыша идем. Яраткан шагыйрем укы дигәч, мин оялуымны онытып, тәрҗемәдәге беренче тәэсирне дә югалтмаска тырышып, мин дәртләнеп:

„Марш эчендә көчле әйләнегез!
Буш сүзләргә монда урын юк,
Ораторлар, акрын!
Сезнең
сүз,
Иптәш маузер...
дип шигырьне яттан укып чыктым.

— Һәйбәт яңгырый! — дип ул минем кулымны кысты. Без сөйләшеп киттек. Шунда ул Казан хәлләрен сорашты, татар әдәбияты турында сораулар бирде һәм үзенең дә Казанга килергә җыенуын әйтте.

„Сул марш"ны татарча тыңлау тәэсирен Маяковский соңыннан үзенең „Казан" дигән шигырендә чагылдырды.

Беренче очрашуның икенче көнендә Маяковский доклад буенча фикер алышуга катнашты. Аның чыгышын без түземсезлек белән көттек. Аны тыңлау гаҗәп рәхәт. Трибун—шагыйрьнең үткен акылы, образлы теле, кызыклы мисальләре тыңлаучылар күңелендә ораторлык сәнгатенең онтылмаслык үрнәге булып калалар. Маяковский төшенкелеккә каршы, урынсыз сүзләр куллануга каршы сөйләде һәм киңәшмәнең кайбер „түрәләре" тарафыннан макталган берничә китапны тәнкыйть уты астына алды. „Сугышчан шагыйрьнең тәнкыйтенә түзә алмаган „түрәләр", Маяковскийны җыелыштан куып чыгару мәсьәләсен күтәрделәр. Ләкин Маяковскийның көрәштә чигенеп калмавы һәм делегатлар арасында аны яклаучыларның күплеге бу тупас тәкъдимне шунда ук юкка чыгарды. Маяковский җиңүче булып киңәшмәдә калды.

Революция җырчысының бу киңәшмәдә никадәр хаклы булуын еллар тулысынча растадылар. Аңа каршы чыккан „язучылар" да, алар мактаган „әсәрләр" дә күптән онытылдылар. Ә Маяковский иҗады яши һәм яшәр.

Г. Кутуй.

В. МАЯКОВСКИЙ

Литейщик Иван Козыревның яңа квартирага күчүе турында сөйләгәннәре

Мин—пролетарий үзем.
Яхшы белә халык.
Ничек тусам, шулай
яши идем мин.
Эшчеләрнең
торак
ширкәтеннән алып,
Яңа квартирага
күчеп килдем мин.
Биеклеге—болай!
Ә киңлеге—болай!
Саф һавалы,
якты,
бик шәп елысы.
Бөтен җире һәйбәт.
Барыннан да болай,
Бик охшады миңа
менә монысы:
Айның нурыннан да
ул үзе агырак,
Әкияттәге җирдән
бик күп уңайлырак.
Сөйләп бетреп булмас
монда һәммәсен.
Мин сөйләргә телим—
ванна бүлмәсен.
Бер кранда
суы
үтә салкын аның.
Тотарлык та түгел
икенче кранын.
Салкын суы белән
мөмкин чәч юарга,
Ә кайнары белән
тирне кырып ал.
„Кай." дигән сүз язган
беренче кранга,
Икенче кранга:
„сал."
Асылырлык булып
арып кайтсаң өйгә,
Ям юк
аш һәм чәйнең
быгырдавыннан.
Акчарлактай
чумсаң,
хәтта үлгәннәр дә
Көләр иде
суның
кытыклавыннан.
Гуя социализмга
килгәнсең кунакка!
Шундый рәхәтлектән
кысыла тын да.
Чалбарны элгечкә,
күлмәкне кадакка,
Сабыныңны кулга
һәм...
бултыйх шунда!
Бик озак юынып
утырасың анда.
Теләгәнчә утыр,
теләмәсәң—
кук!
Әйтерсеңлә
Волга
һәм җәй синең янда—
Пароходлар белән
балык кына юк.
Булса да тәнеңдә
ун ел яткан керең,
Юкә кабыгыдай
төшә суелып,
Агач кайрысы күк
кубып төшә корым,
Тәмам бит, нәләтең,
бетә юылып.
Парланасың шунда,
җарланасың тәмам!
Тартасың аннары
бер сапны шуннан.
Синең өскә шунда
салкын яңгыр тама
Тишекле-тишекле
тимер болыттан.
Шул кадәр иркәли
душ дигәнең сине!
Нәрсәгә эч пошсын
шундый чагында:
Колакларны уа,
сыйпалый чәчеңне,
Арка буйлап ага
аннан тагын да.
Ерткыч кебек йонтач
сөлге белән аннан
Корытасың суны
юеш тәнеңнән,
Җәеп куйган тагын,
бүлмәскә табан,
Бөкедән ясалган
шундый бер идән.
Утырткан көзгедән
карый-карый үзең,
Чиста гына аннан
күлмәк аласың.
Һәм уйлыйсың шунда:
— Нинди яхшы безнең
Үзебезнең Совет власте!

Свердловск, 28 январь, 1928 ел.

Ә. Исхак тәрҗемәсе.

ЯҢГЫРЫЙ СИНЕҢ ҖЫРЛАРЫҢ

Ун ел тулды менә бүген
Үлгән көнеңә
Тик һаман авыр юксыну
Бетми күңелдә.
Сөеклебез, ник буйсындың
Кара үлемгә?!
Арабызда булсаң иде
Менә бүген дә.
Һаман яңгырый илемдә
Синең җырларың,
Күрсәң иде чорыбызның
Данлы елларын.
Җиңү тантанасы белән
Шаулый илебез
Тиңдәше юк биеклеккә
Мендек инде без.
Батыр улын бер кайчан да
Онытмас илем,
Син иркенлекне сөюче
Лачын кошы идең.
Күтәрелдең канатланып
Тормыш төбеннән,
Яктылыкны эзләп очтың
Дөнья күгеннән.
Эшче халык буржуйларны
Кыйнаган чакта
Синең сүзләр чигелделәр
Кызыл байракка.
Яш чактан ук Ленин юлын
Дөрес өйрәндең,
Телгәли синең кылычың
Дошман йөрәген.
Халкым тарихка исмеңне
Кабатлап өсти,
— Юк, үлмәде, исән безнең
Маяковский!

Е. Миронов.

Татполиграф ФЗУ мәктәбе укучысы.

Владимир Маяковский

Илебез Совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйренең—Владимир Владимирович Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуны искә ала. Бөек рус шагыйрьләре—Пушкин, Лермонтов, Некрасов арасында Маяковский исме белән яңа поэтик чор башлана.

Совет поэзиясенә нигез салучы булган Маяковский яңа дөньяның тууы һәм яңа кеше турында тәэсирләндерерлек шигырьләр теле белән сөйләде.

Шагыйрьнең тавышы Совет җиреннән ерак җирләрдә дә ишетелде. Аның иҗады Көнбатыш Европада һәм Америкада революцион сәнгатьнең үсүенә гаять зур йогынты ясады. Маяковский үзенең әһәмияте ягыннан Горькийга—әдәбиятта социалистик реализмның нигезен салучы шушы бөек язучыга турыдан-туры якын тора.

В. В. Маяковский 1893 нче елның 19 нчы июлендә, Грузиядә, Кутаиси якынындагы Багдади авылында туды. Семьясе белән бергә Москвага күчеп килгәч, ул, яшь чагында ук яшерен большевистик түгәрәкләр белән элемтә тота башлады, аларның эшендә катнашты, берничә тапкыр кулга алынды һәм хөкем ителде. Бутырки төрмәсендә ялгыз камерада утырганда ул шигырьләр яза башлады. Маяковскийның беренче әсәрләре безгә килеп җитмәделәр: аның шигырьләр язылган дәфтәрен жандармнар алып калганнар. „Яшьлеге сәбәпле" төрмәдән чыгарылганнан соң Маяковский рәсем һәм скульптура училищесенә керә һәм шунда рәсем занятиеләре белән берлектә шигырь язу тәҗрибәләрен дә дәвам иттерә.

Идеясез, вакчыл сәнгаттән тирәнтен канәгатьләнмәү яшьләрне яңа юллар эзләргә мәҗбүр итә һәм гарипләнгән сәнгатькә каршы көчле протест Маяковскийның әдәби эшенең беренче формасы булып әверелә. Аның искиткеч яхшы шигырьләре өндәү булып яңгырыйлар. „Җәмгыять вкусының яңагына сугалар" (аның беренче футуристлык әсәрләреннән берсе шулай дип аталган иде). Буржуаз матбугат Маяковскийның әдәбият мәйданына килеп чыгуын акырып, кычкырып, котырынып каршы ала. Маяковский эшенең шушы беренче чорының иң кызу вактында ул Горький белән очраша.

Горький рус әдәбиятын җыючы, аның яңа һәм саф талантларын ачучы бөек язучы иде. Ул үзенең искиткеч сизгерлеге белән беренче булып Маяковскийны аңлады.

Маяковскийны Алексей Максимович үзенең „Летопись" журналында язышырга чакырды. Анда Маяковскийның „Сугыш һәм солых" дигән поэмасы басылырга тиеш иде. Бу поэмада шагыйрь үзенең тавышын империалистик сугышка каршы күтәрде. Патша цензурасы бу поэманы бастырырга рөхсәт бирмәде. Горький ярдәме белән „Парус" издательствосында Маяковский шигырьләренең беренче китабы басылып чыкты.

Бөек Октябрь көннәре алдыннан Маяковский Москвада „Сәнгать большевиклары" дигән лекция белән чыкты. Революцион давыл башлангач аңа рус интеллигенциясен борчып килгән мәсьәләне: бу давылны кабул итәргәме, юкмы дигән мәсьәләне хәл итеп торырга туры килмәде. Ул үзенең автобиографиясендә: „Минем революциям. Киттем Смольныйга. Эшләдем. Нәрсә туры килсә—шуны" дип язды.

Маяковскийның аннан соңгы биографиясен революция, аның вакыйгаләре, аның көрәше язды. Ул аңа катнашучы, аның җырчысы һәм көрәшчесе булып әверелде. Ул халыкны ачык өндәү плакаты белән, кисеп үтә торган утлы сүз белән коралландырды. Ул 3 меңнән артык „Роста тәрәзәләре" язды. Ул „Сәнгать армиясе буенча приказлар" бирде, кино-картинага алынды, пьесалар язды, уннарча газеталарда һәм журналларда эшләде, шигырьләр һәм докладлар белән илне һәм дөньяны гизде. Циркта аның пантомимасы куелды, совет товарларының тышларында аның үткен рекламалары күренде, урамнарда аның сугышчан маршлары яңгырады. Ул сәнгатьнең сул фронтының башында торды, журналга редакторлык итте, чит ил әдәбияты белән элемтә тотты. Һәм һәр кайда да , һәр нәрсәдә дә аның тавышы яңгырады.

Аның әдәби мирасын эченә алган 12 томнан 11 е социалистик революциядән соң язылган.

Яңалык кертүче шагыйрь Маяковский сәнгатьнең яңа принципларын тудырды һәм игълан итте. Бу яңа принциплар рус әдәбиятының Чернышевский Добролюбов эстетикасы белән, Некрасовның гражданский поэзиясе белән урнаштырылган иң прогрессив, демократик традициясен дәвам иттерделәр. Социалистик революция эпохасында шагыйрьлек эше коммунизм өчен көрәшнең актив бурычларына җавап бирерлек булырга тиеш—аның тирәнтен ышанган карашы әнә шул иде.

Ул әлегәчә булмаган яңа тормышны күрсәтү өчен әлегәчә бер кемгә дә билгеле булмаган, табылмаган методларны армый-талмый эзләде. Ул чын мәгънәсе белән яңалык ачучы, яңалык кертүче булды.

Маяковский яңа „тел Америкалары" эзләде, уйлап тапты һәм ачты. Чөнки анарда үзләрен күрсәтүне таләп иткән яңа идеяләрнең, яңа хисләрнең киң дөньясы кайный иде. Ул үзе белән бергә әдәбиятка революция белән ачылган шушы дөньяны—аның күк күкерәү тавышларын, аның көрәшенең рәхимсез батырлыгын, героик гайрәт һәм яхшы күңеллелек, яшәүгә, көрәшүгә, җиңүгә булган бетмәслек сусауны һәм җиңелмәслек хәзерлекне китерде. Ул тормышның кан тибеүен бик тиз сизә белде, иҗтимагый тормышта һәм кешенең аңында әле үсә генә башлаган нәрсәләрне күрә белде.

Маяковский безнең илебезнең революцион чынбарлыгын, аның бөек эшләрен, аның көндәлек тормышын, аның белән тудырылган яңа хисләрне сәнгатьнең җанлы формаларына кертте.

Маяковский әсәрләренең эчтәлеге коммунизм идеяләреннән гыйбарәт. Бөек кешеләр—алар бөек дәртләр, диләр. Маяковский һичбер бетмәслек бер дәрт белән—яңа кешелек дөньясының „кояшлы иленә" мәхәббәт белән тулган иде. Коммунизм аның поэзиясенең тәне булып әверелде, ул үзенең бөтен матур талантын безнең бәхтебезнең тантанасы өчен көрәшкә бирде.

Совет халкының үзенең җиңелмәслек Ленин—Сталин партиясен чолгап алган хисләрен аның кебек шундый зур көч һәм сафлык белән, шундый тирән бер хөрмәт белән совет шагыйрьләреннән берсе дә күрсәтә алганы юк. Большевиклар партиясе Маяковский өчен иң кыйммәтле нәрсә булды.

Маяковский партиягә үзенең иң яхшы әсәрләрен багышлады. Җиңүчән социалистик революциянең һәрбер адымында ул партия, Ленин инициативасын, Ленин фикренең һәм теләгенең тантанасын күрде.

Маяковский сәнгатьтә Ленин образын эзли башлаган беренче совет художнигы иде. Аның „Владимир Ильич Ленин" поэмасы үзенең колачы белән, кайнап торган энергиясе һәм көче белән гаҗәпкә калдыра. Совет поэзиясендә Ленин турында моның кебек башка әсәр юк әле.

1930 нчы елның 21 нче январенда Маяковский Ленин истәлегенә багышланган кайгылы утырышта шул поэманы укыды. Анда Политбюро членнары бар иде. Бөек халык шагыйрен иптәш Сталин тыңлады. Маяковский бик тәэсирләнде:

— Бу минем иң җаваплы чыгышым, диде ул.

Зал шагыйрьне көчле кул чабулар белән озатты. Ленин эшен даһи дәвам иттерүче Сталин Маяковскийга кул чапты.

Шагыйрь Сталинда партиянең тупланган фикрен һәм теләген күрде. Үзенең шигырьләрендә ул шушы фикер эзеннән барды һәм Сталин положениеләренең һәм формулировкаларының Маяковский шигырьләренә кергәнлекләрен, аның шигырьләр юлына әверелгәнлекләрен ачык күрергә мөмкин.

„Телим,
кешеләрнең
каләмемне
штык белән,
Чуен белән,
корыч кою белән тиңләвен,
Телим,
шигырьләр турында
Политбюродан
Сталинның
Доклад сөйләвен".

Шагыйрь шулай дип хыяллана иде.

Маяковский совет халкының хисләрен һәм фикерләрен иң намуслы рәвештә һәм чын күңелдән чагылдыручы булды.

Шуның өчен социализм дошманнары аны күрә алмадылар, алар аны эзәрлекләделәр. Аларга һәр вакытта да сугышчан партия постында торучы бу яхшы һәм батыр агитаторны юлдан алып ташлау кирәк иде.

Хәтта Маяковский үлгәннән соң да дошманнар аны пычратырга маташтылар.

Иптәш Сталинның, Маяковский безнең Совет эпохасының иң яхшы, иң талантлы шагыйре булды һәм шулай булып кала, аның истәлеген һәм аның әсәрләрен игътибарсыз калдыру—җинаять, дигән сүзләре Совет поэзиясенең кояшын капларга маташкан болытларны таркаттылар.

Хәзер ул безнең алдыбызда үзенең бөтен бөеклеге белән балкып тора, социалистик поэзиянең юлын яктырта.

И. Бачелис, С. Трегуб.

LEFTTOPPLACEHOLDER

Генерал Каупишның чит ил журналистлары белән беседасы

БЕРЛИН, 12 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенчә, Германия гаскәрләре Даниянең башкаласын алганнан соң 48 сәгат үткәч анда Берлиннән махсус поезд белән 20 чит ил журналисты килгән. Аларны Германия генералы Каупиш кабул иткән һәм Данияне оккупацияләүнең сәбәпләре турында сөйләгән.

Генерал болай дигән:—союзникларның планнары турында вактында информация алынганлыктан Германия гаскәрләре үзләренең операцияләрен тиз үткәрә алдылар. Дания гаскәрләре бик аз каршылык күрсәттеләр. Аларның бары 10 кешеләре үтерелде һәм берничә кешеләре яраланды. Даниянең 5 мең кешесе үтерелү турындагы хәбәрләр бөтенләй уйдырма гына. Германия гаскәрләренең бер кешеләре үтерелде һәм 10 кешеләре яраланды. Аннары генерал Германия гаскәрләренең Даниягә ничек итеп кергәнлекләрен сөйләгән. Моторлаштырылган частьләр бер көн эчендә Даниядә кимендә 350 километр үткәннәр.

Шуннан соң генерал Каупиш Дания короле янында булганлыгын сөйләгән һәм болай дигән: „Аның белән очрашканда Германия гаскәрләре белән Дания халкы һәм учреждениеләре арасындагы мөнәсәбәтләр турындагы мәсьәләдә тулы килешү барлыгы беленде. Дания армиясе һәм флоты киләчәктә дә яшәрләр, чөнки мин аларның лойяль позиция алуларына ышанам“.

СКАГЕРРАК, КАТТЕГАТ БУГАЗЛАРЫНА һӘМ ТӨНЬЯК ДИҢГЕЗГӘ АНГЛИЯНЕҢ МИНАЛАР КУЮЫ

ЛОНДОН, 12 апрель. (ТАСС). Хәзерге вакытта пароходлар өчен куркынычлы булып әверелгән Скагеррак, Каттегат бугазларына һәм Төньяк диңгезнең кайбер урыннарына Англия флотының миналар куюы турында бүген Англиянең диңгез министрлегенең рәсми белдерүе иглан ителде. Куркынычлы районның көнбатыш чиге Голландиянең территориаль суларыннан 5 градус көнчыгыш озынлыктан төньякка таба 56 градус төньяк киңлеккә кадәр һәм аннан 4 градус көнчыгыш озынлыкка таба, 60 градус төньяк киңлеккә кадәр сузыла. Куркынычлы районның төньяк чиге 60 градус төньяк киңлек буенча Норвегия ярына кадәр бара һәм аннан яр буйлап көньяк-көнчыгышка таба, Швециянең территориаль суларына кадәр сузыла. Көнчыгыш чик Швециянең территориаль сулары буйлап үтә. Көньяк чик Каттегат бугазында 57 градус төньяк киңлек буенча, Скагеррак бугазында һәм Төньяк диңгездә Дания һәм Германия ярлары һәм Голландиянең территориаль сулары буйлап үтә.

Нейтраль илләрнең сәүдә пароходларын Швециягә үткәрү өчен 20 миль киңлектә, мина куелмаган махсус коридор калдырыла.

MIDPLACEHOLDER

НОРВЕГИЯ ГАСКӘРЛӘРЕНЕҢ ХАМАР ШӘҺӘРЕН АЛУЛАРЫ ТУРЫНДА БЕЛДЕРҮ

НЬЮ-ЙОРК, 11 апрель. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Швециядә чыга торган „Дагенс нюхетер“ газетасы, Норвегия гаскәрләренең Хамарны янадан алганлыкларын яза.

Эпохабызның иң яхшы шагыйре В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга карата. Рәсемдә: В. В. Маяковский Америкада. (ТАСС фото-клишесе).

В. В. МАЯКОВСКИЙГА БАГЫШЛАНГАН ҖЫЕЛЫШЛАР

14 нче апрельдә ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты һәм Татарстан Совет Язучылары Союзы эпохабызның бөек шагыйре В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга багышлап бөтен шәһәр күләмендә җыелыш үткәрәләр.

Җыелышта „В. В. Маяковскийның иҗад һәм тормыш юлы“ дигән темада иптәш Г. Кутуй докладыннан соң татар совет шагыйрьләре В. В. Маяковскийга багышланган шигырьләрен һәм артистлар Маяковский әсәрләрен укыячаклар.

Җыелыш Менжинский исемендәге клубта, кич сәгат 7 дә башлана.

* * *

Казан Дәүләт Педагогия институтының тел һәм әдәбият факультеты 16 нчы апрельдә эпохабызның иң талантлы шагыйре В. В. Маяковскийга багышланган кичә үткәрә. Кичәдә Маяковскийның тормыш юлы һәм иҗады турында доклад куела. Художество бүлегендә шагыйрьнең әсәрләре укыла һәм башлап язучы студентларның үз шыйгырьләре белән чыгышлары була. Институтта Маяковский әсәрләреннән күргәзмә төзелде. Анда „Маяковский һәм татар әдәбияты“, „Маяковский һәм балалар әдәбияты“ дигән бүлекләр бар.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен кандидатлар

Узган елны Минзәлә районыннан Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә 18 колхоз, 4 терлекчелек фермасы һәм 44 авыл хуҗалыгы алдынгылары катнашкан иде.

Күргәзмәдә катнашырга теләүчеләр быел тагын да күбрәк. Хәзерге вакытта күргәзмәдә катнашу өчен бөртекле культуралар буенча алдынгылардан 99 кеше һәм терлекчелек алдынгыларыннан 107 кеше гариза бирде.

1940 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу өчен билгеләнгән кандидатлар арасында, узган елны икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләнгән товарлыклы-сөтчелек фермасы (Ленин исемендәге колхоз) һәм беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнгән „Чәчкәле“ колхозы бар.

КООПЕРАЦИЯ ӨЧЕН ЯҢА КАДРЛАР

Татсоюз янындагы Казан уку комбинаты 1939—1940 нчы елда раипотребсоюзларга һәм сельполарга инструкторлар, председательләр, бухгалтерлар, колькуляторлар, финанс работниклары, плановиклар хәзерләү курслары оештырган иде. Бу курсларны 1939—1940 нчы елда 420 кеше тәмамлады. 1 нче майга янадан 88 кеше укып чыгачак. Уку комбинаты 5 нче майдан 5 группалы яңа курслар оештыра. Курсларга районнардан 125 укучы килә.

КОЛХОЗЛАРГА АГАЧ һӘМ ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Татсоюз 1939 нчы елны Татарстанның 12 районында колхозларны һәм аерым колхозчыларны агач һәм төзү материаллары белән тәэмин итү өчен складлар ачкан иде. Бу складлар аркылы узган ел 2 миллион 110 мең сумлык кирпеч, акбур, алебастр, бүрәнә, такта һәм башка шундый товарлар сатылды. 1940 нчы елда райпотребсоюзлар янында яңа 5 склад төзелде.

ПРОМКОМБИНАТ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕНДӘ

Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты карамагындагы җирле промышленность предприятиеләрен берләштерү өчен Промкомбинат оештырылган иде. Бу комбинат инструменталь заводны, тегү-скорняк фабрикасын, алкогольсыз эчемлекләр һәм химия товарлары җитештерү заводларын, шулай ук сәгат, язу машиналары төзәтү мастерскойларын берләштерә. Бу предприятиеләр быел 9 миллион сумлык продукция бирәчәкләр. Шулар өстенә алар өстәмә рәвештә бер миллион сумлык киң куллану товарлары эшләп чыгарачаклар. Металлдан төрле савыт-сабалар, кроватьлар, балалар өчен ванналар, умывальниклар, чиләкләр, примус горелкалары, өс-баш киемнәре, трикотаж товарлары һәм башкалар эшләнәчәк.

ДЕПУТАТЛАР ҖАВАПЛЫ ПОСТЛАРГА КҮТӘРЕЛДЕЛӘР

Сталин район советының башкарма комитеты күптән түгел район советы депутатларыннан Жилова, Миңлешев һәм Куликов иптәшләрне совет аппаратының җаваплы эшләренә күтәрде. Иптәш Жилова район сәламәтлек саклау бүлеге мөдире, иптәш Миңлешев район мәгариф бүлеге мөдире һәм иптәш Куликов район коммуналь хуҗалык бүлеге мөдире итеп билгеләнделәр.

ЯҢА КИНО - КАРТИНАЛАР

Союзкинопрокатның Татарстан бүлеге Казан шәһәре һәм район кино-театрларында күрсәтү өчен яңа картиналар алды. 25 нче апрельдән „Электро“ кино-театрында „Хөкүмәт члены“, 29 нчы апрельдән „Унион“ кино-театрында М. Шолохов романы буенча эшләнгән „Күтәрелгән чирәм“ картиналары барачак.

Калган кино-театрларда яңа комедия „Аринка“, „Моряклар“, „Канделәр“, „Бәхет эзләгәндә“ һәм башка картиналар барачак. Бу картиналарның берәр экземплярлары Татарстан районнарына да җибәреләчәк.

Беренче Майга пролетариатның бөек язучысы Максим Горький турындагы картинаның алынуы көтелә.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ МАШИНАЛАРЫ КИТЕРҮ

Соңгы вакытта Татарстан МТС ларына авыл хуҗалыгы машиналарының килүе көчәйде.

Юдино районының Зур Ключи, Арча районының Казанбаш һәм Балык Бистәсе районының Солтан авылларында төзелгән яңа МТС ларга тракторлар, тагылма инвентарьлар һәм чәчкечләр җибәрелде. Быел Татарстан МТС ларына барлыгы 12 миллион 705 мең сумлык авыл хуҗалыгы машиналары алына. Алар арасында 600 трактор, 360 комбайн, 600 чәчкеч һәм башка машиналар булачак. Быел беренче тапкыр булырак киндер йолку машиналары да алына.

Эпохабызның иң яхшы шагыйре В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулуга карата. Рәсемдә: В. В. Маяковский Испаниядә. (Союзфото).

МАЯКОВСКИЙ ТУРЫНДА КҮРГӘЗМӘ

Юдино районының мәктәпләрендә һәм клубларында В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулу көнен үткәрүгә ныклы хәзерлек алып барылды. Васильеводагы тулы булмаган урта мәктәптә укучылар һәм укытучылар әдәби кичә үткәрәләр. Район көтепханәсендә һәм Юдин исемендәге клубта Маяковский әсәрләренең күргәзмәсе оештырылды. Юдин исемендәге клуб янындагы драма түгәрәге 14 нче апрельгә әдәби кичә хәзерли.

Шушы көннәрдә Юдино узелы эшчеләре һәм хезмәткәрләре тимер юлчыларның Үзәк йорты лекторы тарафыннан Маяковскийның тормышы һәм иҗады турында укылган лекцияне зур кызыксыну белән тыңладылар. (Тат ТАСС).

В. В. МАЯКОВСКИЙ ИСТӘЛЕГЕ

В. В. Маяковскийның үлүенә 10 ел тулу уңае белән 12 нче апрельдә мехчылар клубында шагыйрьне искә алу кичәсе үткәрелде. Кичәгә 200 кеше катнашты. Иптәш Савосин В. В. Маяковский турында лекция укыды.

Мехчылар көтепханәсендә Маяковский китапларыннан күргәзмә оештырылды. (ТатТАСС).

ШӘҺӘР һӘМ РАЙОН СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ ӨЧЕН ЛЕКЦИЯЛӘР

Казан Шәһәр Советының Башкарма Комитеты шәһәр һәм район советы депутатлары өчен Сталин Конституциясе, совет төзелеше, шәһәрне төзекләндерү һәм башка темаларда лекцияләр циклы оештырды.

8 нче апрельдә „Казан шәһәренең генеральный планы“ дигән темада иптәш Копец лекциясе булды. Якын көннәрдә „Депутатның хокуклары һәм бурычлары“, „СССР да дәүләт төзелеше“, „1940 нчы елда Казан шәһәрен төзекләндерү“ дигән темаларда лекцияләр укылачак.

ЕЛГАЛАРДА

ВОЛГА суы 13 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Горький янында 29 сантиметр, Югары Ослан янында 8 сантиметр, Кама Тамагы янында 72 сантиметр, Саратов янында 106 сантиметр артты. Югары Ослан, Кама Тамагы, Ульяновский, Куйбышев һәм Саратов янында боз ага. Астрахань яны боздан арчылды. Буксир пароходлар нефть продуктлары төялгән баржаларны тагып, югарыга таба менеп киттеләр.

КАМА суы Молотов шәһәре янында 43 сантиметр, Соколка янында 11 сантиметр, Лаеш янында 81 сантиметр артты. Молотов шәһәре, Соколка, Чистай һәм Лаеш янында көчле рәвештә боз ага.

ВЯТКА суы Вятские-Поляны янында 43 сантиметр артты. Мамадыш янында боз тыгылып тора.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

„Трансэнергокадр“ ның Казан бүлеге
шушы ел 20 нче апрельдән производстводан аерып укытып кочегарлар һәм машинистлар хәзерләү буенча
КУРСЛАР АЧА
Кочегарлар хәзерләү курсларында уку срогы 2 ай. Уку расходлары өчен түләү—271 сум.
Пар машиналарына, локомобильләргә һәм эчке янулы двигательләргә хезмәт күрсәтү өчен машинистлар хәзерләү курсларында уку срогы 3 ай. Укыту расходлары өчен түләү—408 сум.
Курсларга предприятиеләрдән бирелгән командировкалар белән генә алына.
607—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
14, 15 һәм 16 нчы апрельдә
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Иртәгә, 15 нче апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында, Татарстан АССР ның атказанган артисткасы
МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВА
КОНЦЕРТЫ
Кич 9 сәгатьтә башлана.
16 нчы апрельдә
КАЧКЫН
19 нчы апрельдә Зур театр бинасында
ФАУСТ
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

КИРӘК:
Тире-Венера авырулары больницасына (Зур Красный урам, 7). МЕДСЕСТРА, ӨЛКӘН ПОВАР, ЗАВХОЗ, БУХГАЛТЕР, ШВЕЙЦАР, ПИЧ ЯГУЧЫ, АТ КАРАУЧЫ һәм КАСТЕЛЯНША. Хезмәт хакы килешү буенча. 612—1

Күн сбруйлар фабрикасына даими эшкә БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЛАРЫ, ХИСАПЧЫЛАР, ПРОИЗВОДСТВО УЧЕТЧЫЛАРЫ, НОРМАЛАУЧЫЛАР һәм ХЕЗМӘТ ОЕШТЫРУ БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ. Хезмәт хакы килешү буенча.
Ягодный бистәсе, Краснококшай урамы, 39, фабриканың кадрлар бүлеге. 611—1

Тарловка санаторийсында даими рәвештә эшләү өчен ТУБЕРКУЛЕЗ ВРАЧЫ һәм МЕДСЕСТРА. Шартлары турында белешү өчен адрес: Казан, Комлев урамы, Хезмәт сарае, ВЦСПС ның Ял йортлары һәм Санаторийлар Татарстан идарәсе (28 нче бүлмә). 608—3—1

АПТЕКАЛАР ҮЗӘК СКЛАДЫНА АШЫГЫЧ РӘВЕШТӘ БАШ БУХГАЛТЕР. Такдимнәр белән килү өчен адрес: Казан, Астрономия урамы, 15, склад конторасы. 613—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
Бүген, 14 нче апрельдә, шулай ук 17 сендә
КЫЮ КЫЗЛАР
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 8 сәгатьтә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген, 14 нче апрельдә цирк эшләми.
Иртәгә һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
һӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

ТАТАРСТАН АССР СОВНАРКОМЫ ЯНЫНДАГЫ ЖИРЛЕ ЯГУЛЫК ПРОМЫШЛЕННОСТЕ ИДАРӘСЕНӘ ДАИМИ ЭШКӘ КҮМЕР, ТОРФ һәм АГАЧ БЕЛГЕЧЛӘРЕ, ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, ФИНАНС СЕКТОРЫ НАЧАЛЬНИГЫ, БАШ БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕРЛАР, ХИСАПЧЫЛАР һәм МАШИНИСТКА КИРӘК. Кремль, 2 нче подъезд, Торф конторасы. Телефон 32—59. 610—1

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм АРИНКА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	МОРЯКЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ТАШЛАНДЫК
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ЯҢА ЗАМАННАР
„КУЛЬТУРА САРАЕ“ 5, 7 һәм 9 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1514. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1393.